Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге Советы
КАРАР

2025 елның 27 марты № 52/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чуаш Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 27 статьясы нигезендә, Совет Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, график сурәте белән бергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (https://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Гадел авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча чыгарырга:

1. Авыл җирлеге бинасы: Чуаш Ялтаны ав., Школьная ур., 17 йорт,
2. Авыл мәдәният йорты бинасы: Акбулат ав., Октябрь ур., 26 йорт,
3. Кибет: Ишәле ав., Пионер ур., 7Б йорт.

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Чуаш Ялтаны авыл җирлеге
башлыгы С.М. Егоров

Чистай муниципаль районы
Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең
2025 елның 27 мартындагы
52/1 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № т/б | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сай-лаучы-лар са-ны |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче номерлы Октябрь | Ишәле авылы<br>Октябрь урамы 1 нче йорттан 46 нчы йортка кадәр<br>Пионер урамы 1 нче йорттан 23 нче йортка кадәр | 80 |
| 2 | 2 нче номерлы Пионер | Ишәле авылы<br>Пионер урамы, 24 нче йорттан 44 нче йортка кадәр,<br>Красноармейская урамы 1 нче йорттан 21 нче йорт-ка кадәр,<br>Новая ур., 1 нче йорттан 5 нче йортка кадәр | 80 |
| 3 | 3 нче номерлы Центральный | Чуаш Ялтаны авылы<br>Школьная урамы 4 нче йорттан 12 нче йортка кадәр,<br>Керәшен Ялтаны авылы Садовая урамы, 3 йорт | 75 |
| 4 | 4 нче номерлы Молодежный | Чуаш Ялтаны авылы<br>Школьная урамы 1 нче йорттан 3а йортка кадәр, 13 нче йорттан 23 нче йортка кадәр<br>Молодежная урамы 1 нче йорттан 19 нчы йортка кадәр<br>Совет урамы 1 нче йорттан 27 нче йортка кадәр так як | 78 |
| 5 | 5 нче номерлы Совет | Чуаш Ялтаны авылы<br>Совет урамнары 2 нче йорттан 54 нче йортка кадәр җөп як<br>29 нчы йорттан 43 нче йортка кадәр так як<br>Заречная урамы, 1 нче йорттан 31 нче йортка кадәр, Молодежная урамы, 20 нче йорт | 70 |
| 6 | 6 нчы номерлы Овражный | Акбулат авылы<br>Октябрь урамы 1 нче йорттан 25 нче йортка кадәр<br>Овражная урамы 1 нче йорттан 26 нчы йортка кадәр,<br>Школьная урамы 1 нче йорттан 6 нчы йортка кадәр | 66 |
| 7 | 7 нче номерлы Полевой | Акбулат авылы<br>Школьная урамы 7 нче йорттан 20 нче йортка кадәр,<br>Полевая урамы 1 нче йорттан 39 нчы йортка кадәр | 66 |

# Схема одномандатных округов Чувашско-Елтанского сельского поселения

